ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОСПАССКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д. 13, с. Новоспасск, 423535

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Молодежная урамы, 13 нче йорт,
Яңа Спас авылы, Зәй районы, 423535
ИНН/КПП: 1647011467/164701001

Телефон, факс 64-5-48. Электронный адрес: Nspas.Zai@tatar.ru, сайт: www.zainsk.tatarstan.ru/rus/novospasskoe.htm

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
от 27.10.2025 г. №20

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә вакытлы корылмалар һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләр урнаштыру урыннары һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләр урнаштыру схемалары исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урнаштырылырга мөмкин булган объектлар төрләре исемлеген җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә раслау турында» 03.12.2014 № 1300 карары нигезендә, «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 05 июнендәге 416 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән җир кишәрлекләре бирелмичә һәм сервитутлар, гавами сервитут билгеләмичә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә вакытлы корылмаларны һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләрне стоянкалар һәм (яисә) саклау (булу), индивидуаль мобильлек чаралары, төрле спорт инвентарьлары оештыру өчен билгеләнгән урыннар һәм вакытлы корылмаларны һәм (яисә) урнаштыру схемалары исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе Танчук Н.В.

Кушымта
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының
Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитетының
2025 елның «27» октябрендәге 20 номерлы карарына

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге территориясендә машина кую урыннары һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләр, шәхси мобильлек чаралары, төрле спорт инвентарьлары оештыру өчен билгеләнгән урыннар һәм вакытлы корылмалар һәм (яисә) вакытлыча конструкцияләр урнаштыру схемалары исемлеге**

| № п/п | Объектның урнашу урыны | Объектның мәйданы кв. м | Объектның төре | Объектның урнашу урынының координаталары |
|---|---|---|---|---|
| Яңа Спас авылы | | | | |
| 1. | Су арты ур., 14Б | 6 | ФАП бинасы | 55,1454256, 52,2112514 |
| 2. | Яшьләр ур., 14 | 6 | Яңа Спас авыл мәдәният йорты | 55,1441135, 52,2124108 |
| 3. | Яшьләр ур., 13 | 6 | Администрация бинасы | 55,1438508, 52,2122827 |
| 4. | Су арты ур., 14 | 6 | Яңа Спас башлангыч мәктәбе | 55,1447257, 52,2101030 |